# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы Саба  районы буенча**
**Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының**
**суд участоклары чикләре турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 23 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Саба  районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре тасвирламасын әлеге Законга кушымта нигезендә расларга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2010 елның 31 декабре
№ 111-ТРЗ

"Татарстан Республикасы
Саба районы буенча Татарстан Республикасы
җәмәгать судьяларының
суд участоклары чикләре турында"
Татарстан Республикасы Законына
кушымта

**Татарстан Республикасы Саба районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре тасвирламасы**

**1 нче суд участогы**

1 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләр территорияләре керә: Саба муниципаль районының Олы Шыңар, Югары Симет, Яулаштау, Эзмә, Иштуган, Курсабаш, Мичән, Тимершык, Шәмәрдән һәм Шекше авыл җирлекләре.

**2 нче суд участогы**

2 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләр территорияләре керә: Саба муниципаль районының Байлар Сабасы шәһәр тибындагы поселогы, Арташ, Олы Кибәче, Олы Нырты, Килдебәк, Мишә, Түбән Шытсу, Сатыш, Иске Икшермә һәм Юлбат авыл җирлекләре.